**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «25» июненнән № 147

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясеннән узучы муниципаль маршрутлар буенча җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 елның 18 мартындагы 75 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясеннән узучы муниципаль маршрутлар буенча җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 елның 18 мартындагы 75 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясеннән узучы муниципаль маршрутлар буенча җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен

каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү буенча комиссия турында нигезләмәдә 13 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«13. Комиссия түбәндәге карарлар кабул итә:

1) әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар булмаган очракта, оешмаларның гаризаларын кире кагу турында;

2) җирле бюджет акчаларын бирү турында, бирелә торган акчалар күләме;

3) җирле бюджет акчаларын бирүдән баш тарту турында.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (инфраструктур үсеш буенча) йөкләргә.

Җитәкче Е.А. Тарнавский